Исполнительный комитет
Александро-Слободского
сельского поселения Заинского
муниципального района
Республика Татарстан

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Александр Бистәсе авыл
җирлеге башкарма
комитеты

Ул. Центральная, д. 73 с. Ал. Слобода,
Заинский район, 423503

Узәк урамы, 73 нче йорт,
Ал.Слобода авылы, Зәй
районы, 423503

Телефон, факс 6-27-30. Электронный адрес: Aslob.Zai@tatar.ru

**№ 14** **от “22” август 2022 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 09 апрелендәге 05 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 09 апрелендәге 05 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 3 пунктында « муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 3 бүлектә:

а) 12 пунктның икенче абзацында « муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«соңгы 5 ел вакыт эчендә ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләрнең саны һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны нисбәте белән характерлана торган түләүчеләрнең бирелгән ташламаларга ихтыяҗы яисә түләүчеләрнең гомуми саны.»;

в) 12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Түләүчеләрнең бирелгән ташламаларга ихтыяҗын бәяләүне уздыру максатларында салым чыгымнары кураторы тарафыннан ташламага ихтыяҗ дип таныла торган әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин»;

г) түбәндәге эчтәлекле 15.1 пункт өстәргә:

«15.1. Кирәк булганда салым чыгымнары кураторы тарафыннан муниципаль берәмлек салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктны өстәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.Г.Варганова**